СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы,
422591

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-

24.04.2024 с. Введенская Слобода №35-296

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Советына Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Югары Ослан муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетына:

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатыннан, бюджет законнары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге карары проектын эшләү һәм карауга тапшыру.

3. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе  авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов